**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___02.04.2015____ **№**__01-02/197______

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы Федераль Законның 29нчы маддәсенең 2 өлешенә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләп чыгу һәм раслау тәртибен рәсмиләштерү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябреннән 880нче номерлы карарына ярашлы рәвештә, б о е р а м :

1. Әлеге боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәтү күрсәтүнең Административ регламентын расларга (алга таба – Регламент).
2. Министр урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен тайпылышсыз кулланып эш итәргә.
3. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге мөдире А.Г.Сафинга Регламентны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион

челтәрдәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтына урнаштырырга.

4. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге мөдире Э.И.Слепневага әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

5. Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлеге мөдире Г.И.Касыймовага Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 10 сентябрендәге 729нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестры" дәүләт мәгълүмати системасы турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестрына кертү өчен Регламентны җибәрүне тәэмин итәргә.

6. Көчен югалткан дип танырга:

"Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында" Татарстан Республикасы юстиция министрының 2012 елның 12 апрелендәге 01-02/26 номерлы боерыгы;

"Административ регламентка үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы юстиция министрының 2012 елның 22 июнендәге 01-02/44 номерлы боерыгы.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка тапшырырга.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
___ елның ____________
№ _________________
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки соралган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: кызыксыну белдергән органнар, оешмалар һәм физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Татарстан ур., 16 й.

Министрлыкның эшләү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дан 18.00 га кадәр, җомга 9.00 дан 16.45 кә кадәр, аш вакыты 13.00 дән 13.45 кә кадәр.

Җәмәгать транспортында “К.Тинчурин» тукталышына кадәр килергә:

Автобуслар - №№ 1, 6, 31, 53, 54, 71, 99;

троллейбуслар - №№ 3, 5;

трамвай - №2.

Керү шәхесне таныклаучы документ буенча.

1.3.2. Министрлыкның Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмәләр өчен телефоннары: (843) 223-04-96, 293-11-79, 223-03-34.

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникацияләр челтәрендә “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасы составына кертелгән рәсми сайты (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты һәм “Интернет” челтәре) адресы: http://minjust.tatarstan.ru, электрон почтасы адресы: minjust@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) Министрлык бинасында урнашкан дәүләт хезмәте турында мәгълүмат такталары аркылы, алар дәүләт хезмәте турында текст рәвешендәге мәгълүматны үз эченә ала;

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minjust.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язма рәвештә (шул исәптән, электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә кагылышлы мәгълүмат Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык биналарында урнашкан мәгълүмат такталарына урнаштырыла.

1.4. 1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәп алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601нче номерлы Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 б.)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре” 2006 елның 22 февралендәге 68 номерлы карары (алга таба – 68 номерлы карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республиканың башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2006, № 10, 0272 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестры турында” 2010 елның 12 апрелендәге 255 номерлы карары (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республиканың

башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 21, 0786 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен рәсмиләштерү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республиканың башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестры (алга таба – Реестр) – барлык Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең һәм алар турындагы аерым белешмәләрнең системалаштырылган исемлеге;

Дәүләт хезмәте турында гариза бирү (алга таба – гариза) – “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру хакында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2нче маддәсендәге 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау.

гариза бирүчеләр – кызыксыну белдергән органнар, оешмалар, физик затлар;

өземтә – Татарстан Республикасы административ берәмлегенең Реестрда булуын раслый торган язма рәсми документ;

белешмә – сорала торган мәгълүматның Реестрда булмавын раслый торган язма рәсми документ.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең исеме | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү | Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Әлеге Регламентка 1нче кушымтада каралган Реестрдан өземтә.<br>Әлеге Регламентка 2нче кушымтада каралган сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә | Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгать итү ихтыяҗы да күздә тотыла, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату вакыты. | Мөрәҗәгатьне Министрлыкта теркәү көненнән алып 15 көн эчендә | Нигезләмәнең 10 пункты |
| 2.5. Законнар һәм башка | Гаризада (ирекле формада) түбәндәге мәгълүмат булырга | |

| | | |
|---|---|---|
| норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен таләп ителгән, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтләре күрсәтелү ысуллары, шул исәптән электрон формада, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе | тиеш:<br>физик затлар өчен:<br>- фамилиясе, исеме, әтисенең исеме,<br>- адресы (тору урыны һәм (яки) электрон)<br>юридик затлар өчен:<br>- оешманың исеме,<br>- адресы (почта адресы һәм (яки) электрон почтасы адресы)<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып саналган шартлар юк | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүченең аларны тапшырырга хокукы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны | Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны тапшыру таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы | | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган килештерүдә катнашучы дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен гаризада әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы мәгълүматның булмавы нигез булып тора ала (шәхси мөрәҗәгать очраклары искәрмә була ала) | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү түләүсез башкарыла | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләп чыгару методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә һәм мондый хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чират буенча иң озак көтеп тору вакыты | Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүченең кабул ителүне (гариза бирүченең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр реестрыннан өземтә яки яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә алу өчен) иң озак көтеп тору вакыты 15 минут тәшкил итә. Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләренең чиратлары каралмаган | РФ Президентының 601нче номерлы Указының 1нче пункты |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен, шул исәптән, электрон формада булганны | Мөрәҗәгать кергән көндә | |

| | | |
|---|---|---|
| да, теркәү вакыты | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләр көтеп тора һәм кабул ителә торган урыннарга, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштырылуга карата куелган таләпләр | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү:<br>һаваны суыту-җылыту системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Интеграцияләнгән дәүләт телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд белән җиһазландырылган бүлмәдә башкарыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, | Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытының саклануы;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;<br>3) Административ регламентның дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы (охшаш очраклар, шикаятьләр санының Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына карата чагыштырмасы);<br>4) гариза бирүче шәхсән үзе мөрәҗәгать иткән очракта министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеше (консультацияләрне исәпкә алмаганда) ике тапкырдан да | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) кабул итү һәм документлар бирү урыннарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>2) кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>3) мәгълүмати стендларда һәм “Интернет” челтәрендәге мәгълүмати ресурсларда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып мәгълүмат алу мөмкинлеге юк. | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтү үзенчәлекләре | Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү хакында мөрәҗәгать шулай ук электрон рәвештә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының интернет аша кабул итүе аркылы бирелә (алга таба – Интернет аша кабул итү).<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi.tatar.ru), дәүләт һәм | Нигезләмәнең 10нчы пунктының 2нче абзацы |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша (http://www.gosuslugi.ru) электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеген файдаланган очракта, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон формада бирелә. | |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, аларны башкару эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкаруга карата куелган таләпләр, шул исәптән, административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән, электрон формада да, түбәндәге процедуралардан гыйбарәт:

1) гариза бирүчене консультацияләү;

2) гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, гариза язарга да;

3) мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

3) Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат әзерләү;

4) Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат белән бергә юллау.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы әлеге Регламентка 5 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу максатыннан, Министрлыкка шәхсән үзе, почта аша, телефон аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша (яки) электрон почта аркылы мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның мөрәҗәгатенең нинди ысул белән килүенә бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефон аша, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать формасына һәм эчтәлегенә, рәсмиләштерү мәсьәләләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать формасына һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы консультация, шулай ук, күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьне Министрлыкка шәхсән үзе, почта аркылы, порталның интернет аша кабул итүе аркылы юллый.

Мөрәҗәгать Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы аша бирелә ала.

3.3.2. Министрлыкың Оештыру эшләре һәм документлар әйләнеше бүлеге (алга таба - Оештыру бүлеге) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгатьне кабул итә һәм терки;

мөрәҗәгатьнең документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, дәүләт хезмәте күрсәтелү көне һәм вакыты куелган күчермәсен гариза бирүчегә тапшыра яки (гариза бирүченең теләге буенча) почта аркылы юллый;

мөрәҗәгатьне электрон формада “Электрон Хөкүмәт” Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша (алга таба – электрон документ әйләнеше) Татарстан Республикасы юстиция министрына (алга таба – министр) юллый.

Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булмаган мөрәҗәгать теркәлми.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган мөрәҗәгать.

3.3.3. Министр мөрәҗәгатьне карап, аны карау өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасарына юлланган мөрәҗәгать.

3.3.4. Министр урынбасары мөрәҗәгатьне карый да, карау өчен Бүлек мөдиренә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек мөдиренә юлланган мөрәҗәгать.

3.3.5. Бүлек җитәкчесе җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм башкару өчен мөрәҗәгатьне аңа тапшыра.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать теркәлгәннән соң, ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә башкару өчен юлланган мөрәҗәгать.

3.4. Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә әзерләү һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелү турында хат язу

3.4.1. Бүлек белгече:

Реестрдан өземтә яисә сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә әзерли;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат проектын әзерли (алга таба – хат проекты) һәм аны, килештерү өчен, Бүлек җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган вакыттан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Реестрдан өземтә яисә сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм килештерү өчен Бүлек җитәкчесенә юлланган хат проекты.

3.4.2. Бүлек җитәкчесе әзерләнгән Реестрдан өземтәнең яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәнең дөреслеген тикшерә, гариза бирүчегә юлланасы хат проектын килештерә һәм аларны, килештерү өчен, министр урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Реестрдан өземтәнең яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәнең һәм хат проектының Бүлек җитәкчесенә килештерү өчен кергән вакыттан алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм хат проекты.

3.4.3. Министр урынбасары кушымта рәвешендә Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә теркәлгән хат проектын килештерә һәм аны Бүлеккә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән хат проекты, Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

3.4.4. Бүлек белгече килештерелгән хат проектын, Реестрдан өземтәне яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне министрга кул кую өчен юллый.

Әлеге Регламентның 3.4.3 – 3.4.4 пунктларында билгеләнгән процедуралар килештерү өчен министр урынбасарына Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә юлланган вакыттан алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга кул кую өчен юлланган хат проекты, Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

3.4.5. Министр Реестрдан өземтәгә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәгә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүчегә юлланачак хатка кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура хат проекты, Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә министрга кул кую өчен юлланган вакыттан алып бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр кул куйган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә һәм гариза бирүчегә хат.

3.4.6. Бүлек белгече өземтәне әлеге Регламентка 3нче кушымтага ярашлы рәвештә Реестрдан өземтәләр бирүне исәпкә алу журналында; белешмәне – әлеге Регламентка 4нче кушымтага ярашлы рәвештә Реестрда сорала торган мәгълүматның булмавы турындагы белешмәләр бирүне исәпкә алу журналында терки һәм министр кул куйган хат белән Оештыру бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәгә һәм хатка министр кул куйган көннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә юлланган теркәлгән Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә, шулай ук гариза бирүчегә хат.

3.5. Реестрдан өземтәне яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны гариза бирүчегә юллау

3.5.1. Оештыру бүлеге белгече министр кул куйган дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны терки, әлеге хат Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә белән бергә гариза язучы күрсәткән почта адресы буенча юллана яки, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән булса, кулына тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура министр кул куйган дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат белән Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә Оештыру бүлегенә юлланган соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Реестрдан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә, дәүләт хезмәте күрсәтелү турында хат.

3.6. Электрон формада алынган мөрәҗәгатьне карау

3.6.1. Электрон формада алынган мөрәҗәгатьләр әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә теркәлә һәм карала.

Күпфункцияле үзәкләр аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Дәүләт хезмәте күрсәтү таләпләрен куючы Регламент нигезләмәләренең һәм башка норматив хокукый актларның саклануын һәм үтәлешен, шулай ук, җаваплы затларның карар кабул итүләрен көндәлек тикшерүдә тотуны Бүлек җитәкчесе яки Оештыру бүлеге мөдире гамәлгә ашыра.

4.2. Көндәлек тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4.3. Тикшерүләр планга кертелгән һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планга кертелгән тикшерүләр Министрлыкның ярты еллык һәм еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Планнан тыш тикшерү гариза бирүченең төгәл мөрәҗәгате нигезендә үткәрелә.

4.4. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачыклыгы аша, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе турында актуаль һәм дөрес мәгълүмат белән һәм мөрәҗәгатьләрнең (шикаятьләрнең) судка кадәрге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында каралу мөмкинлеге булуы белән тормышка ашырыла,

## 5. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары һәм дәүләт гражданнар хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармауларына) карата шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлык, шулай ук Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл башкармауларына) һәм карарларына судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы. Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, гамәлләренә (гамәлләрне башкармавына) карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белдерә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылса;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылса;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган документлар таләп иткән очракта;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарткан очракта;

5) федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең аларга яраклаштырылып кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында баш тартырга нигез булмаган килеш дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгән өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе буларак бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки төзәтүнең билгеләнгән вакыт эчендә башкармавы;

5.2. Дәүләт хезмәте алучылар яки шикаятьне почта аркылы, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып, интернет аша кабул итүе аркылы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, күпфункцияле үзәк аркылы юлларга, шулай ук, шикаять белән шәхсән үзләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.3. Дәүләт хезмәте алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл башкармауларына) шикаять бирелә торган Министрлыкның, министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта), аның яшәү урыны турында белешмәләр яисә гариза бирүче юридик затның исеме, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап юлланылырга тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт гражданнар хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл башкармаулары) турында белешмәләр;

министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт гражданнар хезмәткәренең карары яки гамәле (гамәл башкармавы) белән гариза бирүченең килешмәве өчен нигез булган сәбәпләр.

5.4. Дәүләт хезмәтен алучы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы.

5.5. Министрлыкка килгән шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көн эчендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре булган вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш, министрлыкның, аның вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки язуда җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуы, яки төзәтүләрне билгеләнгән вакытта башкармавына ризасызлык белдереп шикаять бирелгәндә карау вакыты теркәлгән вакыттан биш эш көнен тәшкил итә.

5.6. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслаучы документларның күчермәләре теркәп бирелә ала. Андый очракта аңа теркәлгән документларның исемлеге күрсәтелә.

5.7. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте алучы тарафыннан яки аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалана.

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләренә таянып, министр (ул булмаганда – вәкаләтле зат) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карар гамәлдән чыгарыла ала, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Карарның күчермәсе язма рәвештә, гариза бирүченең теләге буенча электрон формада да, шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча нигезле җавап карар кабул ителгәннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, әлеге пунктның 1нче һәм 2нче подпунктларында күрсәтелгәнчә, гариза бирүчегә юллана.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре
реестрыннан өземтә яки сорала
торган мәгълүматның булмавы
турында белешмә бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасының**
**муниципаль берәмлекләре реестрыннан**
**өземтә**

____________ № _______
(дата)

Әлеге өземтә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан
_______________________________________________________________________
(орган, оешма исеме яисә физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
бирелә,
аның нигезендә 20__ елның «____» _________ нә (на) Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрында түбәндәге белешмәләрнең булуы раслана:

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы
юстиция министры _____________ ________________
Мөһер урыны (имза) (И.Ф.Ә.и.)

Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре
реестрыннан өземтә яки сорала
торган мәгълүматның булмавы
турында белешмә бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрында сорала торган мәгълүматның булмавы турында**
**белешмә**

_____________ № ________
(дата)

Әлеге күчермә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан

______________________________________________________________________________
(орган, оешма исеме яисә физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
бирелә,
аның нигезендә
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
турында сорала торган мәгълүматның 20__ елның «____» __________ нә (на) Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрында булмавы раслана.

Татарстан Республикасы
юстиция министры _______________ ___________________
Мөһер урыны (имза) (И.Ф.Ә.и.)

Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре
реестрыннан өземтә яки сорала
торган мәгълүматның булмавы
турында белешмә бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтәләр бирүне исәпкә алу**
**ЖУРНАЛЫ**

| № т/б | Гаризаның министрлыкка кергән көне, керү номеры | Кызыксыну белдергән органнар, оешмалар һәм физик затларның исеме | Мөрәҗәгатьнең эчтәлеге | Реестрдан өземтә бирү көне, номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |


Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре
реестрыннан өземтә яки сорала
торган мәгълүматның булмавы
турында белешмә бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта


**Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрында сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмәләр бирүне исәпкә алу ЖУРНАЛЫ**


| № т/б | Гаризаның министрлыкка кергән көне, керү номеры | Кызыксыну белдергән органнар, оешмалар һәм физик затларның исеме | Мөрәҗәгатьнең эчтәлеге | Реестрдан өземтә бирү көне, номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |

Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре
реестрыннан өземтә яки сорала
торган мәгълүматның булмавы
турында белешмә бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына
5 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең эзлеклелек блок-схемасы




Бүлек мөдире
Бүлек белгече
Бүлек мөдире
Министр урынбасары
Бүлек белгече
Министр
Бүлек белгече


Оештыру бүлеге белгече

Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре реестрыннан
өземтә яки сорала торган
мәгълүматның булмавы турында
белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
кушымта (белешмә)

**Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре реестрыннан өземтә яки сорала торган мәгълүматның булмавы турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы юстиция министрлыгы**

| Вазыйфа, Ф.И.Ә.и. | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Глухова Лариса Юрьевна | (843) 293-12-23 | L.Gluhova@tatar.ru |
| Министр урынбасары<br>Ибәтов Мөхәррәм Мансур улы | (843) 293-11-81 | M.Ibyatov@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе<br>Касыймова Гөлнара Ильинична | (843) 223-04-96 | Gulnara.Kasymova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес | Сайт |
|---|---|---|---|---|
| 420014, Казан ш., Ирек мәйданы, 1нче йорт | Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге мөдире | (843) 264-77-46 | pisma@tatar.ru | www.prav.tatarstan.ru |